КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 август

г.Казань

№ 990

Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәренең «М.К.Таһиров исемендәге 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен Татарстан Республикасы милкенә кабул итү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясының 1 өлешендәге 4 пункт нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «М.К.Таһиров исемендәге 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен алга таба аның нигезендә Әлмәт шәһәренең «М.К.Таһиров исемендәге 1 нче лицей» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе (алга таба - мәгариф оешмасы) төзү белән Әлмәт муниципаль районы милкеннән Татарстан Республикасы милкенә кабул итү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

мәгариф оешмасын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә ашыра;

мәгариф оешмасының мөлкәте милекчесе функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы гамәлгә ашыра.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

60 көн эчендә мәгариф оешмасы уставын расларга;

ел саен мәгариф оешмасы уставында каралган төп эшчәнлек нигезендә гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен расларга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

60 көн эчендә 423462, Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Әлмәт шәһәре, Таһиров ур., 33 й адресы буенча урнашкан «М.К. Таһиров исемендәге 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен милек комплексы буларак Әлмәт муниципаль районы муниципаль милекннән Татарстан Республикасы милкенә кабул итәргә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

5. Мәгариф оешмасын гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты белән берлектә әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка оештыру чараларын гамәлгә ашырырга.

7. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә әлеге карарның 3 – 6 пунктларын үтәгәннән соң 30 көн эчендә әлеге карарның 1 пунктына туры китерү өлешендәТатарстан Республикасының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр тапшырырга.

9. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин